ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АККҮЗ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423744, Аккүз авылы,
Үзәк ур.,1 нче йорт.
Тел/факс 3-44-42

СОВЕТ АККУЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423744, село Аккузово,
ул.Центральная,дом 1.
Тел/факс 3-44-42

---

**Решение** **Карар №11**
**25.06.2024**

**«Актаныш муниципаль районы Аккуз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлеге Советының 2023 елның 29 март 5 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә рәисләренең, рәис урынбасарларының, контроль-хисап органнары аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 № 281, 14.06.2018 № 481, 17.10.2018 № 940, 29.12.2018 № 1320, 17.11.2021 № 1087, 13.12.2021 № 1222, 17.09.2022 № 1015 карарлары, кертелгән үзгәрешләр белән), Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2023 елның 29 март 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «12688» саннарын «13323» саннарына алмаштырырга;

2.2 пунктының 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктының 6 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Аккүз авыл җирлеге
Советы рәисе Г.И.Имамова

Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлеге Советы карарына 29.03..2023 ел, № 5
1 нче кушымта (Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлеге Советы 25.06.2024 № 11 карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль берәмлек башлыкларының, депутатларының, авыл җирлекләрендә даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазыйфа атамасы | Айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) | | |
|---|---|---|---|
| | авыл җирлекләрендә | | |
| | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 21 723 | 19 991 | 18 260 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 16 185 | 14 366 | 13 324 |
| Депутат | 13 323 | 13 323 | 13 323 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 13 323 | 13 323 | 13 323 |